СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.05.2023 г. Зеленодольск № 288

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 62 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 26 августындагы 92 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2004 елның 24 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламенты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 62 номерлы карары белән (2021 елның 26 августындагы 92 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статья

1) 1 нче кисәкне яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутатлар, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе сенаторлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары була алмый, Россия Федерациясенең бүтән дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкара алмый. Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты бер үк вакытта район Советы депутаты вәкаләтләрен башкара алмый, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның

гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, башка федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш.»;

2 нче кисәкнең 2 пунктындагы б пунктчасында «Президент» сүзен «Башлык (Рәис)» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. 5 статья.

1.2.1. түбәндәге эчтәлекле 1.1 кисәк өстәргә:

«1.1. Район Советының барлык утырышларында депутат алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез булмаган очракта, Район Советы депутатының вәкаләтләре, район Советы карары белән, вакытыннан алда туктатыла.»;

1.2.2. 5 нче кисәктә «Президент» сүзен «Башлык (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. Депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

1. Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) белешмәләр тапшыра.

2. Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы район Советы депутатлары, депутат итеп сайланган көннән һәм аңа вакантлы депутат мандаты тапшырылылганнан соң, дүрт ай эчендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

3.Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы район Советы депутатлары, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 кисәгендә каралган очракларда, Россия Федерациясе законнары нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыралар.

Хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 кисәгендә каралган килешүләр, хисап чорына кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (тормыш иптәшенең) гомуми кеременнән артып киткән гомуми суммасы башкарылмаган очракта, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы район Советы депутаты бу хакта, Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) хәбәр итә.

4. Район Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматтан, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрдән файдалана алуны тәэмин итү, район

Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Район Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү бурычын үтәве (тиешенчә үтәмәве) турында гомумиләштерелгән мәгълүмат, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирүче персональ мәгълүматлар һәм индивидуальләштерергә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар булмаганда).

2. 1.2.1 пунктының гамәлдә булуы 2023 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**